ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 94-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Л.А. Якунин, К.Ә. Ногаев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 94-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 17 июле
№ 340-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы
депутатлары
Л.А. Якунин,
К.Ә. Ногаев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына**
**үзгәрешләр кертү турында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш), № 74 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 23 статьяның $6^1$ пунктында:

а) беренче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «Күрсәтелгән чикләү» сүзләрен «Әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән чикләү» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган

йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

2) $23^1$ статьяның $5^1$ пунктында:

а) беренче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

б) өченче абзацта «Күрсәтелгән чикләү» сүзләрен «Әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән чикләү» сүзләренә алмаштырырга;

в) дүртенче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

3) 31 статьяда:

а) 4 пунктта:

икенче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Күрсәтелгән чикләү» сүзләрен «Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән чикләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрнең, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы

йөкләмәләрнең» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрнең (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрнең (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктта:

икенче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрне, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрне (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрне (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Күрсәтелгән чикләү» сүзләрен «Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән чикләүләр» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «концессия килешүләрен үтәгәндә (концедент түләве, капиталь грант күләмендә) барлыкка килә торган йөкләмәләрнең, муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрнең» сүзләрен «концессия килешүләрен үтәгәндә барлыкка килә торган йөкләмәләрнең (концедент түләве, капиталь грант күләмендә), муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең яклары булган юридик затлар алдындагы йөкләмәләрнең (гавами партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләренә алмаштырырга;

4) 49 статьяның җиденче абзацында «, шулай ук бюджет акчаларының баш администраторлары тарафыннан касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләр бирү составын һәм вакытларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) түбәндәге эчтәлекле $51^3$ статья өстәргә:

«$51^3$ статья. **Бюджет процессын мәгълүмати тәэмин итү**

Татарстан Республикасында бюджет процессын мәгълүмати тәэмин итү дәүләт һәм муниципаль (иҗтимагый) финанслар белән идарә итү өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә файдалану юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

6) 55 статьяның 2 пунктындагы дүртенче абзацта «1 апреленнән» сүзләрен «1 февраленнән» сүзләренә алмаштырырга;

7) 67 статьяда «, ләкин Татарстан Республикасы Рәисе аны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына керткәннән соң 30 көннән дә артыграк булмаган вакытта» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 68 статьяның 2 пунктында «закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларның бәяләмәләре» сүзләреннән соң «, шулай ук Татарстан Республикасы Хисап палатасы бәяләмәсе» сүзләрен өстәргә;

9) 69 статьяда «яисә ул вәкаләт биргән затларның докладын,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе докладын,» сүзләрен өстәргә, «һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе докладын» сүзләрен төшереп калдырырга;

10) 72 статьяда:

а) 1 пунктның беренче абзацында «, әмма күрсәтелгән закон проекты беренче укылышта кабул ителгәннән соң 30 көннән дә артыграк булмаган вакытта» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы регламенты нигезендә икенче укылышта кабул иткән көнне аны тулаем кабул итү турында карар кабул итәргә мөмкин.»;

11) 73 статьяның 1 пунктындагы беренче абзацында «, ләкин күрсәтелгән закон проектын икенче укылышта кабул иткәннән соң 15 көннән дә артыграк булмаган вакытта» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 74 статьяга түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Агымдагы финанс елында бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирүне таләп итә торган суд актларын (затларга китерелгән зыянны компенсацияләү максатларында чыгарылган суд актларыннан тыш) үтәү Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән каралган ассигнованиеләр чикләрендә суд акты белән билгеләнгән максатларга туры килә торган чыгымнар статьялары буенча гамәлгә ашырыла.»;

13) 77 статьяның 3 пунктындагы өченче абзацында «(муниципаль)» сүзләрен төшереп калдырырга, «товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны үзәкләштерүгә бәйле рәвештә һәм » сүзләрен « товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны үзәкләштерүгә бәйле рәвештә, дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү

өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны үзәкләштерү нәтиҗәсендә бюджет акчаларын сакчыл тоту барлыкка килгәндә һәм» сүзләренә алмаштырырга;

14) $77^1$ статьяның 2 пунктындагы беренче абзацында «белешмәләрнең составын һәм аларның тапшыру вакытларын» сүзләрен «белешмәләрне формалаштыру тәртибен, составын һәм срокларын һәм аларның тапшыру вакытларын» сүзләренә алмаштырырга;

15) $78^2$ статьяның беренче абзацында «Татарстан Республикасы баш администраторлары» сүзләрен «баш администраторлары» сүзләренә алмаштырырга;

16) $97^4$ статьяның $2^1$ пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе докладын;»;

б) дүртенче абзацны бишенче абзац дип санарга һәм анда «рәисе докладын» сүзен «рәисенең өстәмә докладын» сүзенә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны алтынчы абзац дип санарга һәм аны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының беренче абзацы нигезендә алынган акчалар, керем китерә торган эшчәнлектән алынган акчалар, шулай ук әлеге учреждениеләргә мәҗбүри медицина иминияте кысаларында керә торган акчалар булган әлеге учреждениеләр чыгымнары алар тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына акча йөкләмәләре барлыкка килүне раслый торган документлар тапшырылып гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 статьясындагы 2 пунктының дүртенче абзацы нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә) 2026 елның 1 гыйнварыннан кулланыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**
**аңлатма**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы Бюджет кодексын «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актлары аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм 2025 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 14 һәм 15 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 21 апрелендәге 84-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 84-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 24 июнендәге 158-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 158-ФЗ номерлы Федераль закон) белән кертелгән үзгәрешләргә туры китерү максатларында эшләнде.

84-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә закон проекты белән Татарстан Республикасы Бюджет кодексының дәүләти-хосусый партнерлык һәм муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләр буенча Татарстан Республикасы һәм муниципаль берәмлекләр йөкләмәләренә кагылышлы, аларда гавами партнер түләвен һәм капиталь грантны исәпкә алу өлешендә, нигезләмәләре төгәлләштерелә.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 74 статьясына агымдагы финанс елында бюджет ассигнованиеләрен суд акты белән билгеләнгән максатларга туры килә торган чыгымнар статьялары буенча бюджет турында законда каралган ассигнованиеләр чикләрендә бүлеп бирүне таләп итә торган суд актларын үтәү турында нигезләмә кертелә.

158-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Бюджет кодексына түбәндәге үзгәрешләрне кертү тәкъдим ителә:

2026 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы дәүләт программаларын Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законга туры китерүнең иң чик срогы агымдагы финанс елының 1 апреленнән 1 февраленә үзгәртелә;

Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының җыелма бюджет язмасына, тиешле бюджет турында законга үзгәрешләр кертмичә генә,үзгәрешләр кертү өчен нигезләр исемлеге дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларны үзәкләштерү нәтиҗәсендә бюджет акчаларын сакчыл тоту барлыкка килү очрагы белән тулыландырыла;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының касса планын төзү һәм алып бару өчен кирәкле белешмәләрне формалаштыру һәм тапшыру тәртибен билгеләү вәкаләтләре өлешендә вәкаләтләре төгәлләштерелә;

бюджет процессын мәгълүмати тәэмин итү максатларында дәүләт һәм муниципаль (иҗтимагый) финанслар белән идарә итү өлкәсендә дәүләт һәм

муниципаль мәгълүмат системаларын төзү һәм алардан файдалану мөмкинлеге карала.

Моннан тыш, закон проекты белән дәүләт бурычына субсидияләрне, керем китерә торган эшчәнлектән акчаларны һәм мәҗбүри медицина иминияте кысаларында алынган акчаларны тоту максатларында Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләре тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына акча йөкләмәләре барлыкка килүне раслый торган документлар тапшыру зарурлыгы билгеләнә.

Чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын карау һәм раслау тәртибен хокукый җайга салуны камилләштерү максатларында һәм, закон проектында булган хокук куллану практикасын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының бюджет турында закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советында карау һәм кабул итү процедураларын һәм срокларын билгеләүгә кагылышлы аерым нигезләмәләре төгәлләштерелә.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасының башка законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү түбәндәге Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертүне таләп итә:

«Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән идарә итү системасы турында» 2023 елның 30 маендагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;

«Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше касса планын төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2008 елның 7 июлендәге 21-41-56 номерлы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы.

**«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми һәм Татарстан Республикасы бюджетының керем өлешенә тәэсир ясамаячак.